
Шулай диләр безнен картлар.
Быел яз иртә килде. Инде табигать кышкы йокыдан уянып та бетте дисәк була. Елгаларда сулар китте, урманнарда яз чәчәкләре бореләнде. Шулар янәшәсендә талпаннар – урман бете яки клещ та доньяга чыкты. Республикада талпан тешләv очраклары теркәлә дә башлаган инде. Халык әйтvенчә, быел 28 мартта инде талпаннар сезоны ачылган. Мордовия буенча Роспотребнадзор хезмәткәре Валентина Агафонова быел апрель аенын беренче коннәрендә Ромоданово, Ковылкино, Большеберезники, Рузаевка районнарындагы 4 кешене - 2 олы, 2 баланы талпан тешләгән, ә vткән елларда 13-18 апрельләрдә булган, ди. Кvпләр белә – талпан энцефалит дигән куркыныч авыру китереп чыгара, баш һәм арка миен зарарлый. Иртә язда уянган божәк кар тошкәнчегә кадәр зыян салырга момкин.       Талпаннар йокыдан гадәттә апрель аенда уяна. Аларга тереклек итәр очен +1 градус жылы булса, шул житә. Май аенда алар vрчи башлый. Бу вакыт июнь аена кадәр дәвам итә. Талпаннар жәен vзен тыныч тота. Бераз кими дә әле алар. Беренчедән кешегә кадалгач, инде исән калмыйлар. Икенчедән - эссе һава торышы. Талпаннар vзен дымлы һәм салкынча вакытта яхшы хис итә. Талпаннар +7 градустан алып +22 градуста кешегә кадалулары еш кvзәтелә. Бик эсседә алар ял итә. Янгыр алдыннан, дымлы коннәрдә исә һожvмгә әзер торалар. Талпан кадалунын ин куркыныч сәгате иртәнге 8-9 һәм кичке 7 белән 10 арасы. Тагын шунысы бар – энцефалит вирусын йорткән божәкләр жирдән 1,5 метрдан биек булмаган куе vлән арасында яши. Куаклар vскән ачыклык урманга караганда куркынычрак икән. Белгечләр талпан сукмак янында качып утыра һәм vзенен корбанын котә, ди. Баксан, урман бете кеше исен 10 метрдан сизеп алырга сәләтле икән. Талпан теләсә нинди йон яки токкә ябыша да, шуыша-шуыша, тешләv очен ин унайлы урын эзли. Кояш тошә торган жирләрдә талпан аз очрыйлар. Алар урманга караганда, сукмакта мыжлап тора. Шуна урманга барганда башыгызга киегез,киемнәрегез эчкә кыстырылган булсын, аякка резин итек кию хәерле. Аксыл кием киегез. Аннан талпан яхшырак кvренә. Тәнегезне ачык олешенә махсус спрейлар сиптерегез. Әгәр каядыр урман бете кадала икән, тизрәк алдыру ягын каргыз.
Кадалса, ничек алырга, икән: тизрәк табибка барыга тырышыгыз, бару момкинлеге булмаса, vзегез алып карагыз. Башта ул урынга 15 минутка май сортеп куярга кирәк. Талпаннын тәнгә береккән олешен озәргә ярамый. Үзе чыкмаса, тартып алырга кирәк. Божәкне уннан-сулга, сәгать теле унаена борып чыгарасы. Әгәр башы озелеп кала икән, аны спиртка манылган энә белән алыгыз. Үзегез алсагыз да, табибка барыга кирәк! Талпанны лабораториягә экспертизага илтергә кирәклеген онытырга ярамый. Әйтеп

китәргә кирәк Мордовиядә vткән ел халык экспертизага 1454 талпан китергән, аларнын 28 боррелиозлы булган.
Сак булыгыз, киңәшләрне онытмагыз!

**Наилә НАСЫРОВА**